**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН СОВЕТ ГАЙТАНКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ГАЙТӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423014, РТ, Нурлатский район, с. Гайтанкино, ул. Садовая, дом 17,
Тел. 8 (84345) 3-98-01

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«24» октябрь 2022 ел № 1

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гәйтән авыл җирлегенең Гайтән торак пунктында гражданнарның үзара салымы чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гайтән авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гайтән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2022 елның 7 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка клуб бинасы янында Үзәк урамы 13нчы йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлегенең Гайтән авылында Спортивная урамы, 1-75нче йортларда, Рабочая урамы №1-24, Озерная урамы, №1-13нче йортларда яшәүчеләрдән үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2022 елның 8 ноябрендә 12 сәгать 00 минутка клуб бинасы янында Үзәк урамы 13нчы йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлегенең Гайтән авылында Полевая урамында №1-28, Садовая урамы №1-32нче, Заречная урамы №1-7нче йортларда яшәүчеләрдән үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. 2022 елның 10 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка клуб бинасы янында Үзәк урамы 13нчы йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлегенең Гайтән авылында Центральная урамында №1-22, Молодежная урамы №1-39нчы, Мира урамы №1-6нчы, Восточная урамы 2-8нче йортларда яшәүчеләрдән үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен Гайтанкино авылында яшәүчеләр исемлеген аеруны сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

5. Халык җыены этапларын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гәйтән авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты белән тәэмин ителә.

6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2023 елда Нурлат муниципаль районының Гайтән авыл җирлеге Гайтән авылы территориясендә теркәлгән һәм яшәүче һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Җирлек эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән төзелеш контроле өчен түләүне дә кертеп сезонлы карап тоту;

2) Гайтән торак пунктында урамнарны яктыртуны оештыруны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү.

3) Гайтән торак пунктында су белән тәэмин итү чыганагына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр үткәрү.

4) Гайтән торак пунктында паркны төзекләндерү (эскәмияләр сатып алу һәм урнаштыру, үсентеләр сатып алу).

5) Гайтән торак пунктында зират территориясен төзекләндерү.

« РИЗА» «КАРШЫ»

7. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru., Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гайтән авылы мәгълүмат стендларында гражданнар җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Гайтән авыл җирлеге башлыгы Н. В. Авдеева